ГЛАВА
ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПОТАП-ТОМБАРЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2025 ел. Потап-Томбарлы авылы № 1

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы һәм Васькино Туйралы Потап-Томбарлы авыл җирлекләрендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.11, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Потап-Томбарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Потап-Томбарлы авыл җирлеге башлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2025 елның 22 ноябрендә 7 сәгать 00 минутта Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә. Җыенны үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Потап-Томбарлы авылы, Совет урамы, Промзона адресы буенча урнашкан «Березовские зори» ҖЧҖ машина-трактор паркы;

2025 елның 22 ноябрендә 8 сәгать 00 минутта Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын үткәрү урыны - Татарстан

Республикасы, Баулы муниципаль районы, Потап-Томбарлы авылы, Совет урамы, 35 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Потап-Томбарлы мәктәбе» МБМУ;

2025 елның 22 ноябрендә 18 сәгать 00 минута Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә. Җыен үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Потап-Тумбарлы авылы, Совет урамы, 35Б йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты

2. Яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә:

- 1 этап: Беренче май: урамында яшәүчеләр, 1 нче йорттан 30 нче номерлы, Совет урамында яшәүчеләр, 1 нче йорттан 15 нче номерлы Потап-Томбарлы авылы;

- 2 этап: Беренче май урамында яшәүчеләр, 31 нче йорттан 70 нче номерлы, Совет урамында яшәүчеләр, 17 нче йорттан 33 нче номерлы Потап-Томбарлы авылы;

- 3 этап: Беренче май урамында яшәүчеләр, 71 нче йорттан 118 нче номерлы, Совет урамында яшәүчеләр, 34 нче йорттан 118 нче номерлы, Яңа урамында яшәүчеләр, 1 нче йорттан 66 нче номерлы Потап-Томбарлы авылы.

3. Потап-Томбарлы авылы гражданнары җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган баладан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәме, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Потап-Томбарлы авылы территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урыны буенча өч елдан артык яшәмәгән кешеләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт

төзегән Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләре (СВО катнашучылары), һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Потап-Томбарлы авылында яңа зират коймасы):

ӘЙЕ ЮК».

4. 2025 елның 23 ноябрендә 7 сәгать 00 минутта Баулы муниципаль районы Васькино Туйралы Потап-Томбарлы авыл җирлеге торак пунктында гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләү. Җыенны үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Васькино Туйралы авылы, Яшьләр урамы, Промзона адресы буенча урнашкан «Хаҗиев С.М.» крестьян-фермер хуҗалыгының машина-трактор паркы;

2025 елның 23 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Баулы муниципаль районы Васькино Туйралы Потап-Томбарлы авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Васькино Туйралы авылы, Мәктәп урамы, 6А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты һәм Васькино Туйралы авылы гражданнары җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслау.

5. Яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә:

- 1 этап: Үзәк урамында яшәүчеләр, 1 нче йорттан 40 нче номерлы, Түбән урамында яшәүчеләр, 1 нче йорттан 34 нче номерлы, Яшьләр урамында яшәүчеләр, 7А нче йорттан 22 нче номерлы Васькино Туйралы авылы;

- 2 этап: Үзәк урамында яшәүчеләр, 41 нче йорттан 95 нче номерлы, Түбән урамында яшәүчеләр, 35 нче йорттан 38 нче номерлы, Мәктәп урамнары, барлык йортлар, Яшьләр урамында яшәүчеләр, 1 нче йорттан 7 нче номерлы Васькино Туйралы авылы.

6. Васькино Туйралы авылы гражданнары җыенына чыгарылучы мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Васькино Туйралы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган баладан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәме, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Васькино Туйралы авылы территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урыны буенча өч елдан артык яшәмәгән кешеләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләре (СВО катнашучылары), һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Васькино Туйралы авылы, Мәктәп урамы, 25Б адресы буенча урнашкан универсаль спорт мәйданчыгы янындагы территорияне төзекләндерү):

ӘЙЕ ЮК».

7. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырырга (https://www.bavly.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

8. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Потап-Томбарлы
авыл җирлеге башлыгы С.А. Козлова